кыз шул аулак урыныбызга китеп, әчкә үк яшерендек. Тавыш – тын чыгармыйча врач апалар киткәнне көтеп утырдык. Күпме утыргынбыздыр, кычкырып әзләүче булмаган күрәсең, һәрхәлдә бу урыннан безне чакырып алучы булмады. Көз ае бит. Ачыктык, өшедек. Тик әле һаман качкан урыныбыздан чыгарга куркып утырабыз. Менә берчак атын тышауларга килүче әтинең тавышы ишетелде. Төнгелеккә атын шул тирәгә тышаулый ул. Ә атны кич эштән кайтып киткәндә генә тышаулый. Без түбән класслар төштән соң укыйбыз. Димәк, инде балалар күптән таралган, идән юучы апалар да эшләрен бетереп, әти мәктәп ишеген бикләгән. Яшеренгән урыныбыздан чыгып әти янына бардым. Нинди сөйләшү булгандыр. Мәктәп ишеген ачтырып сумкаларыбызны алыйк дисәк, бер Тәслимәнең генә сумкасы калган. Безнекеләрне иркәләребезгә биреп кайтарганнар. Галиянең, Миннурның, минем иркәләребез бездән түбән классларда укый иде. Дәресләр беткәннән соң әле беребездә, әле икенчебездә уйный торган гадәтебез булганга, безнең мәктәптән кайтмавыбызны игътибарга да алучы булмаган күрәсен. Ә ликер кисүне икенче көнне үзебезгә барып эшләтергә туры килде.

## МӘКТӘП ЕЛЛАРЫНЫҢ ИҢ МАТУР ХӘТИРӘЛӘРЕ

Ә мәктәп тормышындагы иң-иң матур хәтирәләр язын урман кисү вакыты белән бәйләнгән. Монысы югары класс укучыларының гына шатлыгы. Бишенче сыйныфны тәмамлар алдыннан, май башлары тирәсендә, югары сыйныф дип аталган бишенче – җиденче сыйныф укучылары, мәктәп киемнәрен эш киемнәренә алыштырып, көнлек азыкны чүпрәк букчаларга салабыз һәм балта – пычкы кебек эш коралларын үткерләтеп, дәрәҗәләребезне саклап кына мәктәп янына җыелабыз. Дәрәҗә саклау үзебездән түбән



сыйныфларда укучылар алдында инде. Янәсе, күрәсезме, без инде укытучы абый-апалар рәтеннән бик тә җаваплы эшкә-урман кисәргә китәбез.

Азыкларыбызны да, эш коралларыбызны да мәктәп аты алып бара. Без инде авылны чыкканчы тәртип белән генә бара алсак та, Куян очының (авылның ул урамы шулай атала) соңгы өйләрен үткән көйгә шаяра-йөгерешә башлыйбыз. Бездән арттарак калып баручы укытучыларыбыз аратирә исемнәребезне әйтеп тәртип сакларга кушсалар да, әллә ни ачуланмыйлар. Кыш озыны мәктәп кагыйдәләрен бозмый яшәргә тиеш балачаганың иркенгә чыккач шаярасы килүен аңлыйлар инде. Хәзерге вакытта урманга барып утын кисүне балалар түгел олылар да, аеруча хәзерге минем яшемдәгеләрдән түбәннәр, бар нечкәлекләре белән белми. Шуңа бу турыда аерым туктап язасы иттем.

Урманга кергәч тә үзебезнең мәктәптә тәгаенләнгән урынга җыелышабыз. Мәктәп мөдире яки лесник безгә эш барышында үзебезне ничек тотарга, тамгаланган агачларны гына кисәргә, агач аударган вакытта тирә - яктагыларны искәртергә кебек күрсәтмәләр бирәләр. Шуннан инде пычкы тартырга ике кеше, балта белән ботаклар тазартучы икәү, киселгән ботакларны җыеп учак ягачак урынга ташыр өчен ике-өч кызны бер төркемгә куялар. Олырак малайлар пычкы белән эш итсә, бишенченекеләр ботак чаба, аларга кыз-лар ярдәм итә. Үзе кызыктыргыч, үзе мавыктыргыч, үзе куркыныч эш кызлар өлешенә тия. Монысы инде җыелган ботакларны бер урынга өеп яндыру. Ул үзенә күрә осталык таләп итә. Аның серләрен безгә әти күрсәтеп бирә. Иң тәү үткән елгы сынып төшеп инде кипшенергә өлгергән вак- төяк чыбыкларны аска салып куябыз. Аннары кисеп аударган каеннан туез сыдырып китерәбез. Ут нечкә чыбыкларга ныклап кабынып киткәч кенә әле яңа киселгән ботакларның вагракларын әкрен генә сала башлыйбыз. Учак өчен ачыграк, якын – тирәдә үскән агачларга зыян килмәслек булган урынны сайлыйбыз. Югыйсә, әле яңа яфрак яра башлаган

ботаклар чытыр-чытыр итеп янып, өскә ут баганасы булып күтәрелә. Үзе кызык, үзе куркыныч. Учагыбыз бик тә шашынып китә башласа, зур гына ботакны өстенә китереп салабыз да, утның "гайрәтен" кайтарабыз.

Шушылай бишенче класстан башланган урман кисү кебек "мөһим" вакыйга мәктәп тәмамлаганнан соң да, минем мәктәптә эшли башлавым сәбәпле озак еллар дәвам итте. Шуны да әйтергә кирәк, көн саен атналар буена унлаган учаклар ягылуга карамастан, бер генә тапкыр да урман янарлык түгел, аерым берәр агачка гына да ут кабынып китү очрагы булмады. Кайбер агачларның яшь яфраклы ботаклары гына кайчак артык эсселектән куырылгалады. Ә учакларны кисәүләре беткәнче яндырганнан соң, туфрак сибеп, кызу күмерләрен томалап бетерәбез. Ә кызыл күмерләрне читкәрәк тартып, кызу көлгә бәрәңге күмеп пешерү үзе бер куаныч. Шулай пешкән бәрәңгенең тәмлелеге! Аны сүз белән генә аңлатып булмыйдыр. Урман кискәндәгесеннән дә тәмлерәге булмагандыр барыбер.

Бәрәңгене кем пешерә бит! Без инде, "зур" сыйныфта укучы кызлар! Аударыласы агач төбенә тамга салынган була. Тамга аскы ягында да, өске ягында да калырлык итеп кискән очракта дөрес киселгән була. Кайвакыт бу кагыйдәне бозарга туры килә.

Алдан кай якка аударырга кирәген чамаламыйча гына кисә башласаң, агачың якындагы башка бер агачка "утыра". Ул чакта инде киселеп беткән агачны да аудара алмыйча байтак вакытны уткәрергә туры килә.

Якын-тирәдә берәр олырак кеше булып ярдәм итмәсә, теге агачны да кисәргә туры килә. Ә ул агач еш кына тамгасыз, хәтта кисәргә ярамый торган, ягъни буралык, такталык төз, юан агач була. Монда инде кем нинди хәйләгә бара. Тиз генә үзең "тамга" салырга да аны башкалар күргәнче туфрак белән "пычратып" куярга кирәк тә була. Ә тамганы аска гына ясап, өскә ясамасаң. Курку аша эшләнгән эштә анысы да була бит. Тамганы кисә торган агачка ике метр чамасы



өскәрәк тә ясыйлар. Һәр агачның төбендәге тамганы иелеп эзләп йөреп булмый бит. Менә шундый "нечкәлекләре" дә булып куя иде. Кайчан ничек тотылмыйча каласың, монысы инде төркемдәге иптәшләр "фантазиясе"нә бәйле.

Олылар биргән киңәшне төгәл үти белгәнбездерме, тәртип шулай нык куелгандырмы, бер генә "ЧП" да булмады минем мәктәп өчен утын кисү еллары тарихында. Ә ул еллар минем өчен үткән гасырның алтмышынчы елларыннан башлап сиксәненче еллар уртасына кадәр дәвам итте. Мәктәпләрдә үзәктән җылыту системасы булдырып, соры күмер, ташкүмер яга башлагач кына, мәктәп балалары язның бу "рәхәт" көннәреннән "мәхрүм" ителде.

Әйе, чыннан да рәхәт көннәр иде ул. Табигатьнең кышкы йокыдан яңа уяна башлаган чагында атна буе, ә ул шулайга сузыла иде, табигать кочагындасың. Агачларның кайберләренә бөреләр әле яңа гына ачылырга әзерләнә, ә каен, зелпе, юкә кебекләрендә бөреләр бөркәнчегеннән арынып, кечкенә ябышкак яфраклар тирә-якка хуш ис сибеп, яз кояшының агачлар арасыннан үтеп кергән сирәк нурларында ялтырыйлар. Әле тегендә, әле монда сирәк кенә ишетелгән кош авазыннан башка шылт иткән тавыш ишетмәссең. Саф һаваны сулап туярлык түгел. Җирдән күтәрелгән дымлы һавага яшь яфраклар исе кушылып сулышны иркәли, тәнгә сихәт булып сылаша. Ә аннары инде берничә урында яшүсмерләрнең әле ныгынып җитмәгән буыннары тарткан пычкының үсеп утырган агач кәүсәсенә тирәнрәк бата барган тавышы ишетелә башлый. Һәркем үз төркемендә шым гына эшли бирә. Аратирә агачларын аударучыларның кисәтү тавышы сагаергә куша. Агач аударучыларның бер-берсеннән шактый ара белән эшләве сакчыллык таләбеннән чыгып эшләнгәндер. Бер төркемдәгеләрнең еккан агачы икенчеләренә һич комачаулаганы хәтердә калмаган. Егетләребезнең шуклыклары да узара төрттереп әйтелгән сүзләргә дә шундый ук җавапларыннан ары сүз озайту булмый.

Күрше авыл мәктәбендә алдык урта белемне, сигезенчегә

бардык анда. Мәктәп йортында бик иске генә дүрт гадәти авыл өе, тагын бер башкаларга караганда нык биек, зур заллы бер бина бар. Элек ул мәктәпнең берничә класстан торган бер бинасы булган. Яңа мәктәп бинасы төзелгәч, спорт залы итеп үзгәртелгән. Менә шул авыл өйләренең берсендә мәктәпнең завучы Январи Никодимович белән рус теле укытучысы гаиләсе яши. Тагын берсендә мәктәп директоры гаиләсе, өченчесе интернат – кызлар өчен. Без менә шунда яшибез. Без диюем шул: ике яклы бу өйнең һәр бүлмәдә бишәр карават. Бер кешелек карават кечерәк гәүдәле булса ике кызга ятак. Бүлмә саен сигезәр кыз. Уртада озын өстәл, караватларыбыз утыргыч булып та хезмәт итә, чөнки утыргычларны куярга урын юк. Бер кырда мич-плитә. Ул безнең бүлмәне дә җылыта, плитә өстендә ашарга да пешерәбез. Менә шул мичкә ягар өчен көздән утын китереп өяләр. Үзебез аны кыш буе, бер атнага җитәрлек итеп, якшәмбе көн төштән соң, барыбыз җыелып беткәч, чыгып кисәбез. Кар астыннан озын агачларны актарып чыгаргач, икебез үтәр-үтмәс аркылы пычкы белән кисә, бер-ике кеше (бишенче класста укыганнарын да утын кисәргә яраклы "кеше" дияргә ярaca) балта белән ярырга тырыша, калганнарыбыз шул карлыбозлы утынны ишек алдына, бүлмәгә мич артына кертеп өя. Кары-бозы эреп эченә сеңеп утырган утынны, кизү торган иптәшебез яндырып җибәреп, бүлмәне җылытырга, шунда ук ашарга пешерергә тиеш була.

Мәктәп еллары белән бәйле тагын бер хәлне сөйлисем килә. Хәтсез тапкыр сөйләнгән булса да, минем исемә төшкән саен елмаю хасил итә ул. Без бу вакытта күрше авылда сигезенче класста укып йөрибез. Моңача туганнардан, әти-әнидән озак аерылып тормаганга, бик сагынабыз. Дәрес кайгысы калмый. Шуңа күрә атна уртасында кайтып әйләнәбез өйгә. Укытучылар белеп калмасын өчен, караңгы төшкәндәрәк авыл артыннан үтә торган юлга чыгып китәбез. Бу вакытта укытучылар йорттагы эшләрен карый, урамга чыкмыйлар дип уйлыйбыз күрәсең. Нигә күренмәскә тырышабызмы? Бердән, рөхсәтсез кайтып китәргә ярамый, тәртип шундый. Икенчедән, укытучы урамда йөргәнебезне күрсә, икенче көнне дәрестә өйгә эшне сорый. Белмирәк торсаң, иптәшләр алдында "урамда йөргәч дәрес әзерләнми шул" дип йөзне кызарта. Ә сагыну андый каршылыклар алдында көчсез. Димәк, бердән-бер юл – караңгыда кайтып әйләнү. "Сагынучылар" без өчәү. Мин баш бала - иркәләремне нык сагынам, алар миннән соң бишәү. Тәслимә төпчек – тансык кыз, апалары сугышка кадәр үк туганга, авылдан ук киткәннәр, олыгаеп барган әти-әнисе иркәләп кенә тора аны. Галияне үзебезгә иптәшкә кайтырга күндерәбез. Алар да бик күмәк. Сагынганын бик сиздереп бармый ул. Аның апа – абыйлары да, эне – сенелләре да бар.

Миннур бертуган апасында квартирада тора, аларның бала-чагасы янында булгач, безнең хәтле үк сагынмый, ахры. Шулай итеп, авылга без гел диярлек өчәү кайтабыз. Кышкы көн бик кыска бит. Мәктәптән кайткач, дежур иптәшебез төшке ашны әзерләп өлгерткәнче, без спортзалга кереп уйнап чыгабыз. Ашаганнан соң дәрес әзерлибез. Ә инде кайтасы көнне ашарга өлгергәнче үк дәрес әзерли башлыйбыз. Без дәрес әзерлибез икән, димәк кайтырга сөйләшенгән. Кайтып китәбез, безне беркем туктата алмый.

Менә шулай бер кайтып килүебездә чын җеннәргә тап килдек.

Нәкъ ярты юлда безнең Айдәрәле ягыннан килгәндә сөзәк кенә үр төшәргә. Үрне төшеп җиткәч, күпер үтәргә. Менә шул күпер "Габсабир күпере" дип атала, ә аның "җенле" күпер дигән даны тирә-якка таралган. Күпер тәңгәлендә бераз түбәнрәк аккан Тәтер елгасында кайчандыр Габсабир бабай төзеткән тегермән булган. Ташландыкка әйләнгән, янәсе, җеннәр иялəшкән. Тегермәнен сүтеп ташлаганнар күптән, тик "җеннәре калган".

Менә шул күпергә төшә торган үр башыннын курка-курка төшеп барабыз. Төн урталары җитеп киләдер, чөнки Тәслимә үзләреннән урап килгәнче, (алар авылның урта-

сында ук тора) байтак вакыт кирәк. Кыйсыбызның күзенә иң элек күренгәндер, Галия белән икәүләп чарбайлап кычкырып җибәрдек. Безгә Тәслимә кушылгандыр, чөнки ул ныграк куркак, безгә ышыкланып арттарак калып бара торган иде башка вакытта да. Юл уртасына басып өчәүләп кочаклашып кычкырабыз. Бөтен тирә-юньдәге җеннәр үзләре бездән куркып качарлык безнең тавышка. Инде күпердән байтак еракта безгә таба килүне җигүле ат пәйда булды без барасы якта. Җеннәр шулай төрле кыяфәткә керә икән, монысын күп ишеткәнебез бар. Чөнки безнең белән интернатта торган Яшерган авылы кызлары атна саен үзләренең тау буенда күреп килә җеннәрне.

Якшәмбе көн кич килгәч, ике яктагы кызлар бергә җыелышып утырып сөйләшәбез ул турыда. Берсе хәтта үзебезнең янга килде без бергә җыелып утырганда. Анысын да сөйләсәм озакка китәр инде. Сөйләме дә булмый. Шулай ике якта яшәгән кызлар барыбыз бер бүлмәдә зур-зур йомгакларыбызны тотып, бу атнада бәйли торган шәл читләрен башлап, әлеге шул җеннәрне сөйләп утырабыз. Өстәлне тирәләп утырганбыз, йомгаклар өстәл өстендә. Җеннәр турында сөйләгәндә бүлмәдә чебен очкан тавыш та юк. Тирән тынлык. Гөлшәт сөйли бу юлы. Яшерган кызы ул, бер класста укыйбыз. Нәкъ шул чакта ишек кыса гына ачыла башлады да, бәләкәй генә бер яланаяк күренде. Мин ишеккә каршы утырганмын икән гөнаһ шомлыгына каршы. Кем беренче кычкыргандыр, секунд үткәнче, бүлмәдәгеләр барыбыз да өстәл өстендә идек инде. Торабыздыр, үзебез аны аңларлык түгел, яр салып кычкырабыз. Ишек ябылды, аяк юкка чыкты, тик без һаман кычкырабыз.

Менә тыш ишек тагын ачылды. Бу юлы киң итеп. Аннан күршедә генә яшәгән мәктәп директоры килеп керде. (Җен шулай төрле кыяфәткә керә икәнен гел сөйлибез бит). Аны күргәч тагын да ныграк кычкырабыз, чөнки җен бит яныбызга ук керде. Безнең тавышка өйләреннән үк ишетеп, балалары да килеп керде. Әниләре Роза апа кертеп җибәргәндер инде.



Ничек туктаганбыздыр, анысы хәтердә калмаган, курку белән очкан күрәсең. Ярулла абый безне тынычландырып озак кына утырды. Аяк- җеннең кем булуы ачыкланды. Ул күрше бүлмәдә калган дежур иптәшебез булган. Йокыга әзерләнеп, оекларын салганнан соң, безнең янга кереп чыгарга булган. Ишек алдының бозлы идәненә басмый гына, теге бусагадан бусына басарга уйлаган, аның яланаягын без җен итеп күргәнбез. Кычкыруның сәбәбе ачыклангач та тынычланырга түгел. Чөнки без өстәл өстенә менгән вакытта тәгәрәшеп төшеп киткән мамык йомгакларыбыз төрле якка таралган. Мәктәп директоры, укытучылар шәл бәйләргә рөхсәт итми, без яшерен генә бәйлибез. Ә менә бүген бер түгел ике начарлык белән тотылдык. Иртәгә ни булыр, бөтен укучыларны җыеп, каты сөйләшү булыр, комсокомитетка чакырып шелтә бирерләр дигән курку белән иртәгәсе хәерсез булырга тиеш көнне уйлап, йоклар – йокламас төн чыктык. Безнең бәхеттән, мәктәптә бу турыда зур сөйләшү булмады.

Шундый ук җен менә бүген тагын безнең юлыбызда.

Теге ат-җен якынлашкан саен йөрәкләребез чыгарлык булып, бөтен тирә-якка ишетелеп тибә. Ат көч-хәл белән яныбызга якынлаша. Аннан өч ир-ат (җен төрле сүрәткә керә бит) сикерешеп төшеп, яныбызга бер сикерүдә килеп җитте. Нәрсәдер әйтәләр, юаталардыр, тынычландырырга тырышалар исемнәребезне әйтеп, (җен исемне дә белә күрәсең), ни булганын сорыйлар. Ничек тынычландыра алганнардыр, атларына утырта алдылар, үзләре кырдан җәяү баралар. Авылга барып кергәндә, безнең йөзләргә елмаю чыккандыр, ахры.

Алар да җиңел сулап, шаян сүзләр белән безнең күңелләрне күтәрергә тырышалар. Эш ничек булганына ачыклык кертергә кирәк хәзер.

Тәслимә – куркак безгә ышыкланып арттарак баргандa, алдына үрләрнең әллә кайсысында ук күренгән җигүле ат- җеннәрне абайлап алган да, безнең арага керергә уйлап, икебезнең кулбашына тотынган. Без җен тотынды дип

куркып кычкырып җибәргәнбез. Ул җен-атлар үзебезнең мәктәп укытучыларын Стәрлебаштан алып кайтып килә икән. Иртә караңгыда китеп, көне буе җигүле торган ат арыган, бик жай гына атлатып, бездән чак кына алда без барасы юлдан үткәннәр. Юлларда ул вакытта бер үрдән төшәсең, икенчесенә менәсең. Без аларны күреп өлгермәгәнбез, чөнки шатланышып, өйдәге хәлләрне сөйләп барганбыздыр.

Инде куркыныч күпергә җитеп бару чынбарлыкка кайтарып, тирә-юньгә күз салганбыздыр Айның иң якты чагы, тирә-як каян кая күренә. Арып, өшеп кайтып җитеп барган укытучы абыйларыбыз безнең тавышка кире килергә мәҗбүр булганнар. Хәйдәр Сәлах улы Рысаев, Таһир Хәбир улы Арсланов, Мосавир Хөбетдин улы Садыков абыйлар өчесе дә үзебезнең укыткан абыйлар. Чын мәгънәдәге олы җанлы укытучылар иде алар. Авыр туфрагыгыз җиңел булсын, безнең кадерле кешеләребез. Ә Таһир абый хәтта класс җитәкчебез. Бу юлы да судан коры чыктык. Куркытырлык тикшерү, әрләү булмады. Тик башкача болай төнлә йөрмәскә, кайтырга кирәк очракта, тәрбиячегә әйтеп, рөхсәт белән көндез кайтып килергә куштылар. Бу өч ел йөреп уку чорында андый кызыклы-кызганычлы хәлләр еш кына кабатланып торды. Башкасын сөйләп тормам, төп темага якынрак килим.

**Гайнетдинов Фанис Гайнуллович.**

Родился 25 января 1946 года в деревне Айдарали Стерлибашевского района БАССР. В семье воспитывалось 6 детей. Неполное среднее образование получил в Айдаралинской семилетней школе. Продолжил обучение в Тятер – Арслановской средней школе, которую закончил в 1963 году. С 1963 по 1968 г. учился в Башкирском сельскохозяйственном институте по специальности инженер – механик. По окончании института трудовую деятельность начал в Коми АССР в Устькуломском РО “Сельсхозтехника” заведующим мастерским, откуда призван в Советскую Армию в октябре 1968 года.

С 1970 г. по 1974 г. работал в Стерлибашевском р/о “





Сельхозтехника” инженером – контролером, заведующим мастерской.

В 1974 году направлен в колхоз им. Крупской Стерлибашевского района в качестве главного инженера колхоза, где проработал до 1978 года. Откуда переведен в аппарат Стерлибашевского райкома КПСС инструктором.

В 1979 году избран председателем колхоза “Ключевые горы” Стерлибашевского района. В 1981 году работал заведующим мастерским. С 1985 года избран освобожденным секретарем парткома колхоза “Ключевые горы”. В 1991 – 2002 гг занимал должность заместителя председателя по социальным вопросам.

Женат, воспитал 3 детей. Умер 2 марта 2004 года в д. Айдарали.



Мин, **Булатова Рәхимә Гыйлемҗан кызы,** 1945 елда Стәрлебаш районы Бузат авылында туып үстем. Өлгергәнлек аттестатын 1963 елда Тәтер – Арслан урта мәктәбендә алдым. 1964 елда БГУ – филология факультетына укырга кердем, 1969 елда тәмамладым. Яшерган урта мәктәбендә уку – укыту буенча дирек-

тор урынбасары булып эшләдем. Лаеклы ялга Яшерган урта мәктәбеннән киттем.

Тормыш иптәшем белән бер кыз үстердек.

Я, **Давлетъяров Галиаскар Сарварович,** родился 25 января 1946 года в д. Яшерганово в многодетной семье. Отец, служащий, пенсионер, умер в 1958 году. Мать, колхозница, умерла в 1999 году.

Жена, Гульсима Мубараковна, работает на стройке, на заводе, вышла на пенсию. Сыновья: 1970 г.р. инженер, своя семья, 2 сыновей ( внуки), 1975 г.р. своя семья, 2 дочерей (внучки), тоже инженер – электрик.

Трудовая деятельность:

В 1963 году устроился учеником электрика на Стерлитамакский Опытный Завод. В 1965 году достиг 5 разряда по специальности. С 1965 по 1968 гг служба на Северном Флоте на подводной лодке, специалист стартового оборудования балл. ракет атомной п/лодке.

С 1969 по 1978 год рабочий электрик (бригадир комсомольско – молодежной бригады). С 1978 – мастер . С 1980 до ухода на пенсию старший мастер (2011г), (начальник отделения ремонта эл.цеха завода «Каустик»).

Образование:

1969 – 70 гг. вечернее училище по специальности.

С 1974 по 1979 гг. СХТТ техник – механик.

Три раза повышение квалификации по специальности. (все аттестаты и свидетельства выше 4,5 балла).

Награды и поощрения:

Около 45 грамот различного уровня.

3 раза на Доске Почета, сфотографирован у знамени Победы.

Заслуженный Ветеран Труда.

Занесен на Книгу Памяти.

Общественная работа:

Секретарь комсомольской организации.

Председатель цехкома.



Член Совета Директоров.

Член Общественного Совета.

Играю в шахматы, где то 1-2 разряд. На пенсии с 2011 года.

С 1975 года – член КПСС. Награжден серебряным значком ЦК ВЛКСМ "Молодой гвардеец пятилетки". 33 рационализаторских предложения. В настоящее время проживаю в г. Стерлитамак.



**Ибрагимов Фәнис Шарифулла улы** 1945 елның 15 июлендә Башкорт АССР ның Стәрлебаш районы Тәтер – Арслан авылында дөньяга килгәнмен. Бала чагым шушы авылда узып 1963 елда урындагы урта мәктәпне тәмамлап 1963 – 64 елларда авыл советында библиотекарь, геофизика оешмасында топограф булып эшләдем. 1964 – 67 нче елларда Совет Армиясенең РВСН гаскәрләрендә хезмәт иттем. 1967 елны өлкән сержант званиясендә демобилизацияләнеп "Арслан" колхозында малчылык өлкәсендә эшләдем һәм 1968 нче елны Чиләбе каласының трактор заводында сверловщик вазыйфасын үтәдем.

1969 – 74 елларда Чиләбе педагогия институтының география – биология факультетын кызыл дипломга тәмамлап туган авылым Т – Арсланга кайтып тарих укытучысы булып эшли башладым.

1975 – 86 елларда директор урынбасары булып эшләгәннән

соң 1986 елда Т - Арслан авыл Советының рәисе булып сайландым.

1994 елда Т - Арслан урта мәктәбенең директоры итеп тагәенләндем һәм 2005 елга кадәр шул вазыйфаны башкардым. 1984 нче елдан РСФСР ның магәриф отличнигымын, хезмәт ветеранымын.

Тормыш иптәшем Ибрагимова (Баймуратова) Разия Гөмәр кызы беләν ике улыбыз – Рафаэль, Ильдарны үстердек, алар авыл хуҗалыгы институтын бетереп, оныкларыбыз Диана, Карина, Ренат, Самира ул – кызларыбызны үстерәләр.

2007 – 2013 елларда авыл Советы каршындагы Ветераннар Советын җитәкләп 2005 елдан пенсиядамын.

***Ибрагимов Ф.Ш.***

## Классташларым.

Классташлар кызлар һәм малайлар.
Бармы җирдә сездән якыннар?
Ягфәр, Таһир, Галия, Нәзирәләр,
Фәнисләр, Тәслимәләр, Гафурлар!
Классташлар, яшьтәш, замандашлар.
Табиблар, мөгәлимнәр, әдипләр,
Талгатъ, Марс, Инсаф, Ризалар,
Минегөл, Хәтимә, Нәсимә, Фәритләр.
Классташлар дуслар һәм иптәшләр,
Сезне хөрмәтләп, зурлап баш иям
Миннур, Галиаскәр, Наҗия, Наиль,
Роза, Хөсәен, Рәхимә, Әльфиям.
Классташлар, күрше авылдашлар
Озак курик тормыш дәвамын
Анварә, Гөльшат, Гөләмзәләр
Гел дә Мосавир тартсын баянын!





**Ишмухаметов Наил Хабдулбасырович.**

Родился 28 мая 1946 г. в деревне Булгарово Федоровского района Башкирской АССР.

В 1953 году начал учиться в 1 классе Булгаровской начальной школе Федоровского района БАССР. Первой учительницей была замечательный человек – педагог Хафизова Назия Хажиевна. До сих пор помню ее светлый, добрый образ этой женщины.

В1957 году продолжал учебу с 5 класса в Тятер –Арслановской школе Стерлибашевского района БАССР. Окончил эту среднюю школу в 1963 году.

Затем в этом же году поступил учиться в Салаватский индустриальный техникум БАССР и получил специальность техника – технолога химической промышленности.

Потом служба в ВМФ СССР. Учился в учебном отряде подводников атомного флота. После получения специальности отправили на Северный Флот СССР. Служил 3 года торпедистом атомной подводной лодки Северного Флота.

Годы службы 1966 – 1969 .

1970 – 1975 годы учеба в Бирском Государственном педагогическом институте. После демобилизации с 1969 по 1971 годы работал учителем физкультуры и биологии в Тятер – Арслановской и Кабакушевских средних школах.


С 1972 по 1994 г. работал в детской колонии № 1 г. Стерлитамака МВД БАССР. Отсюда в 1994 ушел пенсионером. Пенсионером МВД.

В настоящее время работаю охранником Стерлитамакского филиала БГУ. Здесь работаю с 2004 года – 13 лет.

Семья – жена Флюра Ахтямовна, сыновья – Ильшат, Аяз, Алмаз.

Внучки – Зарема, Элина. Внук – Артур.

В настоящее время живем в г. Стерлитамаке.



**Султанов Ризатдин Каюмович** родился 1 ноября 1946г. в многодетной семье колхозного крестьянина четвертым ребенком. С 1953-1960 учился в Бузатовской восьмилетней школе. С 1960 – 1963 г. учился в Т-Араслановской средней школе №3 Стерлибашевского района. 1963-1964г. работал в колхозе им.Крупской в качестве разнорабочего, после отмены трудодней и перевод на денежную оплату труда колхозников в 1964 г. работал счетоводом полевой бригады. В 1964г. поступил в ускоренные курсы учителей для сельских школ, после окончания курсов работал учителем в Уч-Асановской восьмилетней школе Стерлибашевского р-на. В ноябре 1965г. был призван на срочную службу в Советской Армии. После службы в Советской Армии работал и заочно учился в г.Уфе. После окончания Всесоюзного института Советской торговли в 1976г. назначен гл.бухгалтером Государственного комитета по делам издательств и полиграфии и книжной торговли Совета министров БАССР. 1984-1985г.г. работал в Торгово-бытовом



предприятии в ГДР. С 1985г. по 1995г. работал гл.бухгалтером в Управлении капитального строительства Уфимского горисполкома. С 1995 по 2010г. работал в АО "Башкиравтодор". С 2011г. на заслуженном отдыхе.

Семейное положение женат. Жена Валишина Люзия Калимулловна в настоящее время проживают в г.Уфе.



Мин, **Мавликаева (Ибрагимова) Галия Сабир кызы,** 1947 елның 11 мартында Стәрлебаш районы Айтуган авылында туганмын. Аннары әти-әнием Кызыл – юл авылына күчеп килгәннәр, мин дә Кызыл-юл да башлангыч классны тәмамлап, Тәтер-Арсланда урта белем алдым. Стәрлетамакта 10 айлык пед-курсны укып, Яшерган авылында башлангыч класста укытучы булып эшләдем. Аннары Стәрлетамак шәһәренә күчеп киттек, анда "СК"заводында эшләп хаклы ялга чыктым. Тормыш иптәшем Тәбрис белән бер ул (Альфред), ике кыз (Розалия, Светлана) тәрбиялəп үстердек. Артур исемле оныгым, Снежана исемле оныкачым бар, алар да хәзер укып чыгып, эшләп йөриләр. Хаклы ялга чыккач, Яшерган авылына кайтып шунда яшәп ятабыз, тормыш иптәшем Тәбрис белән бергә яшәүебезгә дә 50ел булды.

**Мифтахов Инсаф Загрутдинович** родился 1 февраля 1946 года в деревне Бузатово Бузатовского сельского Совета Стерлибашевского района Республики Башкортостан в многодетной крестьянской семье.

После окончания Бузатовской восьмилетней школы в 1961-1963 годах учился в Тятер-Араслановской средней школе.



В связи с нехваткой учителей в 1964 году был направлен на 10-месячные курсы учителей русского языка и литературы в г.Стерлитамак. В тот же год поступил заочно на филологический факультет Стерлитамакского Государственного педагогического института. В 1965-1967 годы работал учителем русского языка и литературы в родной Бузатовской средней школе, завучем Уч-Асановской восьмилетней школы. В сентябре 1967 года он перевелся на очное отделение СГПИ. После окончания института работал учителем, завучем Бузатовской средней школы, директором Уч-Асановской восьмилетней школы.

Говорят, жизнь тем и прекрасна, что полна сюрпризов. Один за другим следовали крупные повороты в его жизни, изменившие судьбу. А судьба забросила его в Аургазинский район. В августе 1979 года он с семьей переехал в село Толбазы Аургазинского района, где в 1979-1990 годы работал инструктором, зав.кабинетом политпросвещения, заведующим отделом пропаганды и агитации райкома КПСС.

После ликвидации райкома партии с 1990 по 1992 год работал главным специалистом Аургазинского районного Совета.

Второй крутой поворот произошел в 1992 году, когда его назначили директором строящейся Толбазинской средней школы №2. Школа уже на третий год после открытия заняла призовое место по подготовке к новому учебному году.

Не заставил себя долго ждать и третий крутой поворот в его жизни: в мае 1996 года он был назначен редактором районной газеты «Путь Родины». «Это было полной неожиданностью, - вспоминает он, жаль было расставаться со школой, коллективом, учениками». В должности редактора районной



газеты он проработал 15 лет.

Жизнь скоротечна. Так незаметно подошел пенсионный возраст, чем он воспользовался, но ненадолго. На Пленуме районного Совета ветеранов, который состоялся в феврале 2012 года, его избирают председателем Аургазинского районного Совета ветеранов войны, труда, Вооруженных Сил и правоохранительных органов. И вот уже 6 лет он возглавляет эту ответственную работу. Много делается в районе по социальной защите, улучшению благосостояния ветеранов, по приобщению ветеранов к активной общественной и духовной жизни, по патриотическому и нравственному воспитанию молодежи, по увековечению памяти ветеранов войны и тружеников тыла. По инициативе районного Совета ветеранов в районном центре с.Толбазы одним из первых в республике открыли памятник труженикам тыла.

На протяжении всей жизни помнит он напутственные слова родителей своим шестерым детям: «Получите знания, трудитесь на совесть». Его родители были рядовыми колхозниками: отец Загрутдин Гизетдинович – участник ВОВ, ветеран



труда. После войны работал военруком в школе, около 30 лет был заведующим фермой, был председателем ветеранской организации Бузатовского сельского Совета. Мать Фатима Хайрулловна – труженица тыла, работала в колхозе.

Супруга Инсафа Загрутдиновича Роза Абубакировна – педагог, окончила СГПИ. Работала учительницей в Бузатовской средней школе, воспитательницей в Аургазинском детском доме, «Отличник просвещения РБ». Сейчас на заслуженном отдыхе.

Они вырастили и воспитали троих детей. Все получили высшее образование. Старшая дочь Зульфия – учительница иностранных языков, окончила БГУ, имеет высшую категорию. Младшая дочь Гульназ окончила Уфимский финансовый колледж, Казанский финансовый институт, работает в министерстве финансов республики. Сын Ильшат окончил исторический факультет Стерлитамакского désинститута, юридический факультет Чувашского государственного университета. Их радуют 3 внучки и 1 внук.

Инсаф Загрутдинович – «Отличник просвещения РФ», «Почетный гражданин Аургазинского района», награжден Почетной Грамотой Всероссийского Совета ветеранов, Почетными Грамотами Министерства печати, Совета и администрации района. Он член Союза журналистов РБ и РФ.

Нашему выпуску 55 лет, а нам самим уже за 70. Годы летят незаметно быстро. Как часто мы их упрекаем за это, удивляясь проступившей седине или воркованию внуков, но вместе с тем и благодарим. Я благодарен судьбе за то трудное и счастливое время, когда уверенно шел по жизни своей трудовой дорогой. Далее пока все неведомо. Но я оптимист, - говорит он.

**Мулюкова Әнвәрә Шәкүр кызы** 15 август, 1945 елда Оренбург өлкәсе, Шарлык районы Ялчыкай авылында тудым.

Күп балалы гаиләдә тәрбияләндем. Әтием Ленинград фронтында 2 группа инвалиды булып сугыштан кайтты.

1953 нче елда Т – Арслан урта мәктәбендә 1 класска төшеп 1963 елда урта мәктәпне тәмамладым. 1965 нче елда Стәрлебаш районы, Куганакбаш авылына башлангыч класс





укытучысы булып эшкә урнаштым.

1969 нчы елны тормышка чыктым – Садыков Марс Абкадир улына. 1980 нче елда беренче булып балалар бакчасы ачтык. Иске мәктәпне ремонтлап, балалар бакчасы " Миләшкәй" не ачтык. Төрле яшьтәге балалар 30 бала кабул иттек.

1985 нче елда Ленин исемендәге колхоз, председателе Ялаев Ф.И. тырышлыгы белән яңа балалар бакчасы төзелде. Анда барлык уңайлыклары булган, 3 группалы балалар бакчасы. Эш чорында, хатын – кызлар Советы председателе булып 20 ел эшләдем. (1980-2000 нче еллар).

Тормыш иптәшем Марс белән 3 бала – Садыков Мансур, Марсель, Айдар үстердек. 3 улыбыз да авылда яшиләр. Әтиләренең, балаларның тырышлыгы белән өчесенә дә өй салдык. 3 улымда Армияда хезмәт иттеләр. 5 оныгыбыз бар.

Мулюкова Әнвәрә Шәкүр кызы:

Отличник Народного Просвещения.

Ветеран Труда.



**Муллагалеев Марс Зәки улы** 1945 елның 13 сентябрендә Айдәрәле авылында туган. Җидееллык мәктәпне тәмамлагач 9 нчы класска Т-Арслан урта мәктәбендә укый. Урта мәктәпне тәмамлагач Петровскийда электрик һөнәрен үзләштерә. Аннан соң Совет Армиясе сафларында Ил алдындагы бурычын үти. Армиядан соң өйләнә. Стәрлебашта яши. Милициядә секретарь булып 1972 елга кадәр эшли.

1972 елдан Коми АССР да шахтада взрывник булып 10 ел эшли. Аннан соң авылга әти – әнисе янына кайта. Авылда Мәдәният йортында худ.җитәкчесе булып эшли. Хәзерге көндә пенсионер, Айдәрәле авылында яши.



**Нугманов Мусавир Миgranович**

**Детство:**

Родился я в одном из красивейших уголков Стерлибашевского района в деревне Кызыл – Яр 1946 году 31 мая в 3 часа дня.

Родители мои простые колхозники, колхоза им. “ 8 марта”. В те послевоенные годы наша деревня и деревня “ Ак чишма” образовали отдельный колхоз им. “8 марта”. Отец мой Нугманов Мигран Гирфанович работал трактористом на колесном тракторе ХТ.З. с





шипованными железными колесами.

Мать Нугманова Гарифа Хуснутдиновна работала поваром на полевом столе колхоза . Родители сутками пропадали на работе, в основном меня воспитывала бабушка со стороны отца. Поэтому, наверное, я вырос мягким, добродушным по характеру романтиком.

Детство прошло как у всех деревенских мальчишек: играли в войну, присматривали за младшими братьями, пасли гусей, пололи и поливали огород, помогали по силе возможностей хозяйству.

Помню, как вчера, как меня готовили в школу, в первый класс.

Бабушка сшила мне тряпочную сумку из толстого сурового материала с лямками, чтобы носить на спине. Перешили мне костюм от старого костюма, который носил мой дядя, счетные палочки сделали из прудков калины. Счастливенький я пошел в первый класс.

Это было первого сентября 1953 года.

**Школьные годы:**

Учился я неплохо, всегда ходил в средняках. На второй год не оставался, переходил из класса в класс. У нас в деревне школа была только начальная. Закончил я четырехлетку на хорошие отметки без троек.

Дальше учиться надо было идти в соседнюю деревню Бузатово, которая находилась от нас в пяти километрах. Там была семилетняя школа. Это расстояние от нашей деревни до школы мы со своими сверстниками измеряли дважды туда и обратно, каждый день, летом хоть на велосипедах, а зимой пешком или на лыжах в лаптях. Темно по утрам, ветер, дождь, буран, но мы все равно занятия не пропускали. Весело было учиться, участвовали в художественной самодеятельности, устраивали концерты, проводили новогодние вечера, елку наряжали сами самодельными бумажными игрушками.

Каждый день в большую перемену организовывали танцы под гармошку. На гармошке, конечно, играл я.

Начиная с пятого класса нас, учащихся привлекали к сельскохозяйственным работам. Помогали колхозу убирать урожай. Переворачивали хлебные валки, убирали картофель, кормовую свеклу и т.д.

Что говорить, мы, ученики заготавливали дрова для печного отопления школы. Лес рубили, грузили, разгружали и складывали в школьном дворе. Это было настоящее трудовое воспитание.

Семилетку успешно закончил в 1960 году. Отец спросил: "Ну что сынок думаешь, будешь дальше учиться или пойдешь на курсы трактористов?"

Я сказал: "Отец, я буду учиться дальше, закончу десять классов, а потом подумаем куда пойти".

В этом же году меня приняли в Тятер – Арслановскую среднюю школу. Собрались мы в восьмой класс ученики из десяти деревень. Несмотря на это, класс был самый дружный, дисциплинированный, успевающий. На школьных линейках наш класс всегда ставили в пример. Годы учебы в этой школе оставили самые прекрасные воспоминания. Мы были юными, почти зрелыми ребятами. Учились, жили полноценной насыщенной жизнью. Активно участвовали в общественной жизни школы. Показывали концерты, каждую неделю в субботу организовывали танцы. Втихаря от учителей и родителей, всем классом собирались и отмечали все праздники, конечно же было и спиртное. Но никто за рамки приличия не выходил. Впервые узнавали сладости, переживания и трагизм первой любви.



1963 год, весна, цветы, прекрасная пора. Успешо сдав выпускные экзамены, мы с успехом закончили школу. До сих пор, я без слез не могу вспомнить наш выпускной вечер. Напутственные слова наших любимых учителей. Сколько было разговоров, слез, признаний в любви. Мечтали о светлом будущем, строили грандиозные планы. Разошлись только с первыми лучами солнца. Сами того не замечая, как шагнули в пучину, которая называется жизнь.

**В распутье:**

Мои закадычные друзья одноклассники: Хисматуллин Ягфар, Ахмадеев Тагир, Ибрагимов Фанис, Гайнетдинов Фанис в тот же год поступили в высшие учебные заведения. А я замешкался и опоздал. А если правду сказать надоело учиться, хотелось быстрей вникнуть во взрослую жизнь. Самостоятельно работать, зарабатывать собственные деньги, чтобы ни от кого не зависеть. Этому способствовал случай: в тот год в нашу деревню приезжала бригада электриков, и начали тянуть электролинию от Бузатова до нашей деревни. Меня приняли в бригаду подсобным рабочим. Через неделю я уже лазил по столбам, тянул провода. Появились деньги, интерес к работе. Так прошло полгода, в один прекрасный день к нам заехал в гости председатель колхоза Юсупов Исмагил абый. Отец мой тогда работал главным инженером колхоза, и они с отцом были в хороших отношениях.

Вот он мне говорит: "Хватит парень тебе дурака валять, тебе нужно учиться. Колхозу нужны специалисты сельского хозяйства. В БСХИ открываются подготовительные курсы, по-

ступишь, будешь колхозным специалистом".

Недолго думая, я взял чемодан яиц, картошку, что бы прокормиться и прибыл в г. Уфу в сельсхозинститут с колхозным направлением. Я до сих пор благодарен Ахмадееву Тагиру в том, что он принял меня к себе в общежитие как родного брата, и мы с ним на протяжении трех месяцев спали на узенькой кроватке, делились последним куском хлеба.

В конце курсов сдал я экзамен на агрономический факультет. Сдал, но по конкурсу не прошел, а домой ехать стыдно, что скажет отец, товарищ Юсупов, друзья, родственники. Долго думал, переживал, как дальше быть, что делать. Уехал в город Пермь, завербовался в строительно – монтажный поезд. Так называлась организация.

**Служба в Вооруженных Силах:**

Проработал я там, около года, поездил по Уралу. Вроде все, хорошо работаю, деньги хорошие платят, домой присылаю понемножку, приоделся, но вижу, нет перспективы, тянуло в родные края, домой. А ехать стыдно. Пошел в военкомат г. Перми, встал на учет и через две недели уже получил повестку в армию. Отправили меня в далекую Грузию на пограничные войска в город Батуми. Там находился морской нефтеналивной и пассажирский порт. Это были морские ворота в страну Советов. После принятия присяги отправили в город Новороссийск на трехмесячные курсы по изучению иностранных паспортов по специальности паспортный контроль. Успешно окончив курсы и получив звание младшего сержанта, вернулся обратно в город Батуми, служил я добросовестно, много было благодарности от командиров части, отличительных нагрудных знаков. В те 1965 – 68 годы очень в почете были у наших граждан нейлоновые рубашки, плащи, цветные шариковые ручки и женское нижнее белье. Вот и мы ловили иностранных и Советских моряков с контрабандным товаром. За добросовестную службу был награжден двухнедельным отпуском домой. Демобилизовался в августе 1968 года в звании старшины.



**Студенческие годы:**

Кто служил далеко от родины тот знает какая радость вернуться в родной дом, в родные края после долгой разлуки. Это была эйфория души, всех хотелось обнять, целовать. Месяц отпуска положенный после демобилизации пролетел как один миг. Надо было думать, что делать дальше. Мои одноклассники, друзья, получив образование по специальности уже работали на должностях. Любимые девочки повыходили замуж, успели уже обзавестись детьми. Надо было найти свое место в этой жизни. Незаметно пришла зима, начались свадьбы, концерты, танцы в клубах, а гармонист в деревне был один, это был я. Была очень веселая жизнь.

В один прекрасный зимний день к нам в клуб нагрянули коллектив Р.Д.К., артисты с. Стерлибашево. Попросили меня заменить заболевшего товарища. Пришлось становиться артистом районного дома культуры. С этим коллективом я объездил все деревни Стерлибашевского, Федоровского районов. Но мысли об учебе в БСХИ никогда меня не покидали. Весной 1969 года я опять поступил в подготовительные курсы БСХИ.

В этом же году успешно сдав вступительные экзамены я поступил в агрономический факультет института. Студенческие годы, наверное, как у всех студентов, незабываемые, можно сказать самые лучшие годы в жизни.

Учился я по среднестатистический, на пересдачу экзаменов, зачетов не ходил, "хвостов" не было. В период учебы приходилось вести большую общественную работу. Начал в первом курсе комсоргом группы. Потом культцектором курса, факультета. А после третьего курса культцектором института. У нас в институте была очень развита художественная самодеятельность. Мы создали прекрасный ансамбль танцев, ансамбль кураистов, баянистов, народных инструментов. Деревенская молодежь очень талантлива. Нас всегда приглашали выступать на телевидение. На городских и республиканских торжественных мероприятиях.

Время шло, мне уже стукнуло 26 лет, надо было думать о

создании семьи. Честно говоря, после первой любви в юности, которая меня не дождалась со службы в армии по обоюдно неприятным жизненным обстоятельствам, никак не мог серьезно влюбиться. Конечно, девушки были, но они глазам нравились, а сердце не принимало. Закончил я четвертый курс, направили меня начальником студ.штаба дер. Миловка учхоз БСХИ, где все студенты проходили летнюю практику. За лето через учхоз проходило около 600 студентов. Всех надо было обустроить, накормить, держать дисциплину в студгородке, организовать досуг молодежи. Работы хватало, к тому же мне самому закладывать опыты под будущий дипломный проект. Однажды, в один из прекраснейших летних вечеров пошел я провожать девушку, местную, после танцев. Бывает же так, в тот вечер я сказал себе: Это она, твоя, которую ты искал. Через три недели после знакомства мы сыграли веселую студенческую свадьбу.

Получив диплом ученого – агронома в 1974 году взяв за руки молодую жену, и один чемодан на двоих приехали по направлению в совхоз Первомайский Стерлитамакского района.

**Работа:**

По приезду в совхоз назначили меня по приказу агрономом – семеноводом. Агрономическую службу совхоза тогда возглавляла заслуженный агроном РСФСР и БАССР Баландина Мария Михайловна. Под ее руководством я работал в течение года. Спасибо ей, многому она меня научила. В 1975 году после ухода на заслуженный отдых Баландиной, доверили мне возглавить агрономическую службу совхоза. Агрономическая служба состояла из 8 человек, 5 отделений 9 деревень. 22960 га земельных угодий, из них 18690 га пашни. Да было тяжело. Не хватало опыта. Учеба одна, а работа на земле имеет свои законы. Не всегда получается по книжке. Да еще командуют сверху, райкомовские товарищи. Как сеять, когда сеять, сколько сеять. Приходилось подстраиваться на ходу. За 33 года работы все было в достатке и взлеты, и падения, десятки выговоров и полторы десятки почетных грамот. За период



моей работы я старался внедрять новшества в технологии возделывания с/х культур. Внедрил безотвальный вспашки зяби, минимальной обработки паровых полей.

Вывел с полей злостный сорняк овсюга, пырей ползучего, больше стали применять минеральных удобрений и ядохимикатов. Постоянно занимались семеноводством, внедряли новые перспективные сорта с/х культур. В результате урожай с/х культур стали стабильными. В 1982 году приняли меня в ряды КПСС, кстати я до сих пор член КПРФ и нисколько не жалею об этом. В 1998 году мне присвоили почетное звание “Заслуженный работник с/хозяйства РБ”.

Отработав 33 года в одном хозяйстве в 2007 году с почестями присвоив звание “Ветеран труда” “Почетный гражданин Стерлитамакского района” проводили меня на заслуженный отдых.

**Личная жизнь.**

Мне кажется личная жизнь тоже удалась, с супругой жили мирно, не ругались, она работала бухгалтером в центральной конторе совхоза. Оба пропадали на работе, а дома командовали тесть с тещей. Они с нами жили в течении 20 лет. Вырастили и воспитали двух прекрасных дочек. Обе закончили Стерлитамакский пед.институт. Живут своими семьями, есть внуки. Вот уже 45 лет живем с хозяйкой, дом построили, детей родили, сад посадили, осталось только просить у Бога здоровье.

**Послесловие.**

После выхода на пенсию я чувствовал себя брошенным всеми забытым человеком. Меня тянуло на поля, в коллектив с кем я работал все эти годы. Но время лечит. Нашел я себе выход общаться с людьми. Я председатель совета ветеранов, староста населенного пункта где я живу. Постоянный член избирательной комиссии. Жизнь стала интереснее, некогда думать о старости.

Я любил свою профессию, любил запах свеже – вспаханной пашни, любил запах спелого пшеничного поля, любил запах степной полыни, любил людей с кем мне довелось работать, и они отвечали уважением и любовью ко мне.

Оглядываясь назад, с вершины прожитых лет мне кажется я прожил насыщенную, интересную жизнь. Если бы мне сказали, вот тебе вторая жизнь – наверняка я повторил бы заново свою прожитую жизнь.

**Хисматуллин Я.С.**

Хисматуллин Ягфар Саягфарович 1946 елның 10 маенда Айдәрәле авылында, колхозчылар гаиләсендә туа. 1953 – 1963нче елларда Айдәрәле җидееллык һәм Т-Арслан мәктәпләрен тәмамлый. Хезмәт юлын математика укытучысы булып 1964 елны Карамалы сигезеллык мәктәбендә башлый. 1965 елның октябрендә ВЛКСМ ның район комитетына бүлек мөдире булып тәгаенләнә. 1969 – 1971 елларда КПСС район комитетында инструктор булып эшли. 1971 – 1972 елларда Совет Армиясында хезмәт итә. 1972 – 1973 елларда КПСС район комитетында инструктор. 1973 елның июнь аенда ВЛКСМ район комитетының 1 секретаре итеп сайлана, монда эшләгәндә яшьләрне тәрбияләгәндә бик күп чаралар үткәрәләр, аның иҗатташлыгы булып. Яшь ударникларның район слеты ел саен үткәрелде, яшь алдынгыларның район Почет тактасы булдырыла һәм бик күп башка чаралар үткәрелә. Уңышлар өчен ВЛКСМ Үзәк Комитетының Күчмә Кызыл байрагы белән бүләкләнә район, ә Хисматуллин Я.С. ВЛКСМ Үзәк Комитетеның “За активную работу в комсомоле” дигән значок белән бүләкләнә.

1977 елны Хисматуллин Я.С. КПСС ның район комитетын оештыру бүлегенә мөдир итеп тәгаенләнә. Һәм шунда 1981 елга кадәр эшли. 1981 елда “Ключевые горы” колхозына председатель итеп сайлана. Колхозны җитәкләү 1987 елга кадәр дәвам итә. Һәм шушы елны РАПО председателенең урынбасары итеп тәгаенләнә һәм анда 1992 елга тиклем эшли.

1992 елдан “Кислород” җәмгыятенең председателе һәм крестьян хуҗалыгының башлыгы булып эшләп, 2017 елдан хаклы ялда.

Хисматуллин Я.С. “Почетный гражданин” Стерлибашевского района, Бөтендөнья Татар конгрессы Башкарма комитетының Рәхмәт хаты белән бүләкләнгән.



# ШӘФКАТЬ ЮЛЫНДА

1994 елдан бирле районыбызда төп рухи байлыгыбыз – әдәбият мәдәният һәм сәнгатьне үстерү, шушы өлкәдә җиң сызганып хезмәт иткән аеруча сәләтле шәхесләрне ачыклау һәм хөрмәтләү йөзеннән шәхси эшкуар милләтпәрвәр Ягъфәр Сәягъфәр улы Хисматуллин тарафыннан булдырылган Мифтахетдин Акмулла исемендәге фонд эшләп килә.

Фондның исемен рәсмиләштергәндә без тарихка таяндык Акмулла – XIX гасырда башкорт, татар казакъ телләрендә иҗат иткән мәшһүр шагыйрь Мифтахетдин Камалетдинов Гомерен горбәтлектә (читтә) һәм сукбайлыкта зая кылган, әмма тугры сүздән хак юлдан тайпылмаган мәгърифәтче якташыбыз. Нәкъ шул сыйфаты өчен халык аңа “Акмулла” дип исем кушкан да инде.

Һич арттыру түгел, районыбыз тормышына яңа бизәкләрне мул өстәде Фонд шушы 20 ел эчендә. Бу бүләккә бары тик Стәрлебаш җирен данлаучыларның гына лаек булуы бигрәк тә дәртләндерде төбәгебездән чыккан язучыларны, ә биредә



*Рәсемдә: Акмулла исемендәге Фондның комиссия әгъзалары сулдан уңга З.М. Фархшатова, Р.Ш. Рысаев, Я.С. Хисмәтуллин, З.З. Гыйзетдинова, Х.Ш. Исмәгыйлев*

яшәгән каләм осталары һәм мәдәният хезмәткәрләрен яңа казанышларга рухландырды. Бүгенге көнгә аның әдәбият буенча бүләгән 10, сәнгать һәм мәдәният өлкәсендәгесен 7 якташыбыз һәм Стәрлебаш Мәдәният йорты каршындагы татар халык театры коллективы (җитәкчесе Нурия Рәхмәтуллина) белән Күндерәк авыл Мәдәният йортының "Күндерәккәй" башкорт фольклор ансамбле (җитәкчесе Люция Байназарова), шулай ук бөтен төрки дөньяга танылган атаклы Камал театры алуга иреште.

Районыбыз гәзитендә үз вакытында дөнья күреп торган премияга тәкъдим итүләр, шул уңайдан кандидатларның иҗатына бәя бирүләр, лауреатларга тантаналы кичәләрдә бүләк тапшырулар каләмкярләргә бетмәс – төкәнмәс дәртдәрман өстәде. Нәтиҗәдә республика остасы Флүрә Сәлимова, Башкортстанның татар телле язучылар берлеге әгъзасы Рәфгать Рысаев, мажаралы әсәрләре белән "Тулпар" журналының даими авторына әйләнгән Хисаметдин Исмәгыйлев, Стәрлетамак язучылар оешмасы әгъзалары Фәрит Әхмәтов, Тимербулат Мөхәммәтколов, шагыйрәләр Зөлфия Гыйззетдинова, Нәсимә Әхмәтова, Фәнирә Ибраһимова, Гөлсинә Басыйрова һәм башкалар районыбызның горурлыгына әверелде.

Соңгы елларда үзнәшер ысулы белән китап чыгару мөмкинлеге барлыкка килгәч, фонд бу җәһәттән дә мактауга лаек эшчәнлеген җәелдерде. 2003 елда, мәсәлән. "Стәрлебаш районының Акмулла исемендәге премия лауреатлары", ә 2006 елда "Язма гөл чәчәкләре" исемле соклandыргыч китаплар дөнья күрде. Аларның Шәйхелислам Шәяхмәтов тарафыннан язылган беренчесе Фондның 20 еллыгы уңаеннан тулыландырылып, менә әле яңадан басарга әзерләнә.

Икенчесенә исә районда яшәгән һәм биредә туып – үсеп читкә киткән 45 иҗатчының төрле жандагы әсәрләре кергән.

Әлеге китапны тәкъдим итү кичәсе алдыннан район китапханәсендә "Түгәрәк өстәл" үткәрелде. Аңарда Башкортстан Язучылар берлеге әгъзасы Флүр Галимов, Татарстан



Язучылар берлеге әгъзасы Зәки Зәйнуллин, күп шигырьләре җырларга салынган, Башкорт дәүләт аграр университеты деканы Рәфис Зыязетдинов, Д.Бүләков исемендәге премия лауреаты Мәҗит Кәримов, шулай ук Флүрә Сәлимова, Рәфгать Рысаев, Гаяз Үләев, Гаян Арсланов һәм башкалар катнашып, киләчәккә районда әдәбиятны үстерүгә кагылышлы киңәшләрен ишеттерде.

Ә Зәки Зәйнуллин район тарихына тукталып, Мифтахетдин Акмулла тормышында безнең мәгърифәтле төбәгебезнең тоткан урынын бәяләде дә 1905 елга кадәр татар шигъриятенең иң көчле, иң зур һәм иң талантлы үзәге Эстәрлебаш авылында булган, дип белдерде һәм әлеге җыентык авторларын да: "Акмулла рухыннан уянучылар", - дип атады. Шулардан чыгып, Стәрлебаш районы язучылары берләшмәсен булдыру тәкъдиме белән чыгыш ясады һәм аны төзү юлларын өйрәтте.

Бу тәкъдим бердәм хупланып, шунда ук оештыру комитеты төзелде. Нәтиҗәдә 2007 елда әдәби-мәдәни оешма рәсми рәвештә расланып, эшчәнлеген җәелдереп җибәрде. Әмма үзенең матур гамәлләре белән халыкта зур абруй яулаган Акмулла фонды моңа карамый, үз юлыннан баруын уңышлы дәвам итте. Берәүләрне Акмулла премиясе белән шатландырса, икенчеләрне түгәрәк гомер бәйрәмнәрен тамашачылар алдында үткәреп тәбрикләп килә.

Халыкта "Ялгыз торна яз китерми" дигән тәкъбир йөри. Бу мәкаль әлеге оешма җитәкчесе Ягъфәр Сәягъфәр улына да кагыла. Эшчәнлегенең уңышлы, халыкка үтемле, нәтиҗәле булуында ул җәмәгате Риммага таяна. Фикердәш һәм сердәш Римма Хәсән кызы мәдәни чараларны оештыруда "азау ярган" шәхес. Ул үткәргән иң катлаулы, иң җаваплы тантана кичәләрендә вакыт исәбе, дөнья мәшәкатьләре, кайгы-сагышлар – һәммәсе онытыла, юкка чыга. Тамашачы зиһенендә фәкать ул тудырган сәхнә мохите генә яши.

Дөрес, тәүге елларда мондый тамашаны Римма да ялгыз башкармады. Аңа үз эшенә мөкиббән бирелгән һәм мавык-

тыргыч сюжетлар кора белгән режиссер Әминә Хәлилова ярдәмгә килде. Кирәк чакта музыкаль компонентлар да катнашты.

Беркемгә дә сер түгел: хәзерге тамашачы зур сәхнә һәм заманча тамаша белән таныш – хәбәрдар булгач, гадәти чыгышларга бик нәзберек, әйтер идем "борынын күтәребрәк" карый. Колак тондыргыч шау-шу, күз камаштырырлык төсле яктылык, кыргый хәрәкәт – менә андыйларның зәвыгы.

Ә Римма оештырган тамашалар модага иярмичә, тыйнак, басынкы, ихлас, урысча әйткәндә "от всей души" итеп үткәрелә һәм тәнәфессез – нисез өч сәгатькә сузыла. Килгән кеше ял итә, фәһем ала, рухын баета.

Стәрлебашта озак еллар татар һәм урыс телләрен укыткан Римма Хәсән кызының тагы бер изгелекле эшен дә искә алу бик мәслихәт – ул алып барган радиотапшырулар ул чактагы радио тыңлаучыларның әле дә күңел түрендә.



***Рәсемдә: Римма һәм Ягъфәр Хисмәтуллиннар.***



Аның тырышлыгы һәм маһирлыгы аркасында бөтен районга яңгыратылган юбилярлар, күренекле якташлар, туйчыларны котлаулар, алар хөрмәтенә башкарылган җырларны һәркем тыңлап кинәнде. Шунысы да сокландырды: Римма һәр заказчының теләгән саф үз телендә - татарча, башкортча, русча ягымлы сүзләр белән ишеттерде.

Чиләгенә күрә капкачы дигәндәй, Авыргазы районының Балыклыкүл авылында туып үсеп, Стәрлетамак педагогия институтында укыганда танышып, Ягъфәрне үз итеп кияүгә чыгуы һич кенә дә очраклы хәл түгел Римманың. Чөнки районыбызның Айдәрәле авылында бөтен Совет халкы Бөек җиңүнең беренче еллыгын бәйрәм итеп бетмәгән чакта 1946 елның 10 маенда Ягъфәрнең дә доньяга " Ур – ра " яңгыратуы гына да сабыйның гомер буе яхшылык кылып яшәвенең төп сәбәбе булып торадыр әле. 1963 елда күрше Т.Арслан урта мәктәбен тәмамлаган егет бер ел Карамалыда укытканда ук үзенең оештыру сәләтен күрсәтеп өлгерде һәм ВЛКСМның Стәрлебаш райкомына бүлек мөдире итеп күчерелде.

1971 – 1972 елларда Армия сафында замполит роты булып хезмәт итүе аның киләчәккә зур этәреш ясап, аннан кайту белән тагында җаваплырак эшләргә этәргеч булды.

Башта КПСС район комитетында инструктор, ә бер елдан соң ВЛКСМның район комитетында 1 секретарь булып эшли. Шушы вакыт эчендә ул үзенең тыныч холыклы, изге җанын, киң белемле, ярдәмчел җитәкче осталыгына ия узалыш икәнен бөтен районга танытты.

Шуңа да 1977-1981 елларда партия райкомында оештыру бүлеге йөген тартты. Аннан соң 6 ел буе туган "Ключевые горы" колхозын җитәкләп, авылдашларының теленнән төшмәде. Совет дәверенең гомер көзе – 1987-1992 елларда кабат Стәрлебашка кайтып, район авыл хуҗалыгы идарәсе начальнигы урынбасары вазыйфасын башкарып, колхозларның абруен күтәрүгә лаеклы өлешен кертте.

Ягъфәр Сәягъфәр улының хезмәт казанышлары хөкүмәт тарафыннан да югары бәһаланды.

Аның күкрәген " Ленинның 100 еллык хөрмәтенә тырыш хезмәте өчен ". "Хезмәттәге казанышлары өчен" медальләре бизәде. БАССР Югары Советы Президиумы, РФ Авыл хуҗалыгы Министрлык Мактау грамоталары белән бүләкләнә.

Ил тормышы кыйратылгач, заман сулышын тоеп, 1992 елда җаваплылыгы чикләнгән "Кислород" җәмгыяте оештырып, газсыман кислород һәм азот эшләп чыгара башлады.

Берничә елдан ике катлы офис, гараж калкып чыкты, җитәрлек техника тупланды. Шулай ук җир алып, игенчелек белән шөгыльләнүне дә иш янына куш итте Ягъфәр. Елның елында мул уңыш үстереп хезмәткәрләрен вакытында акчалата түләнгән эш хакыннан тыш, ашлык, печән, салам белән тәэмин итте.

Алма агачыннан ерак төшми дип белми әйтмәгәннәр. Римма белән Ягъфәргә ифрат тап килә бу әйтем. Кызлары Гүзәл Уфа финанс институтын тәмамлап, Милли банкта әйдәүче



*Рәсемдә: Уртада Я.С. Хисмәтуллин, баш бухгалтер Н.А. Махмудова һәм хезмәткәр М.М. Гизатуллин.*



икътисадчы булып эшли. Ә Гөлназ Башкортостан дәүләт медицина университетында доцент вазыйфасын уңышлы башкара, югары категорияле соклангыч дөнья көтеп, уллар һәм кызлар үстерәләр.

Адәм балаларына йөкләнгән ата-ана бурычын да менә шулай үтәде Стәрлебашның чын-чыннан маягына әйләнгән Ягъфәр белән Римма.

Менә шундый тырыш, тыңгы белмәс пар якташларын 2009 елда "Язма гөл чәчәкләре"нең икенче китабы белән сөендерде. Дөрес, китапны туплауда, чыгаруда мөхәррире Рәфгать Рысаев зур хезмәтен салган шулай ук Флүрә Сәлимова, Хисаметдин Исмәгыйлев үз өлешләрен керткән. Җыентыкта Стәрлебаш районының урыс, башкорт, татар телләрендә язучы 30 иҗатчысының шигыйрь, хикәя, нәсерләре урын алган.

Китап Зәки Зәйнуллинның "Эстәрлебаш – шигърият үзәге" дип аталган күләмле язмасы белән ачыла. Исем-фамилиясе үк төбәкне бизәп торган икенче шәхес – Фәйзи Гомәров. Шагыйрьнең сатирик һәм юмористик шигырьләре бик күпләрне чын мәгънәсендә философ булаган әдип дөньясына алып керә.

Төрле һөнәр ияләренең хаклы ялга чыккач кулларына каләм алып, шигърият дигән серле дә, могҗизалы да дөнья



сәхифәләренә үз исемнәрен язарга җөрьәт итүчеләр дә бар китапта. Бик мәслихәт. Димәк олыгайдым дип, күңелләрен боектырмыйлар, киресенчә, иң тынгысыз өлкәдә үзләрен сынарга уйлаганнар. Андыйлардан авыл хуҗалыгы фәннәре кандидаты, купьеллык үләннәрнең биш сортын "иҗат итүче" Равил Галимуллин шигърият аланында да адашмас диясе килә.

Нәсимә Әхмәтова гомер буе мәктәптә әдәбият укыткан. Балаларга әдәбият, шигърият серләрен ачкан. Фәридә Садриева гомерен сатучы һөнәренә багышлаган. Хәзер икесе дә каләмгә тотынган.

Җыентык берничә бүлектән тора – "Әдәби мирас" дигәнендә Шәйхелислам Шәяхмәтов, Мариус Максютовның шигъри гөлләмәләре хуш исләрен тарата. Ә инде "Абруйлы каләмкәрләр" дә Рәвил Шаммас, Мәҗит Кәримов, Хәлимә Назарова, Нәгыйм Ярмөхәммәтов, Гаяз Уляев, Рәфис Зыязет-



*Рәсемдә: Хисмәтуллиннар гаиләсе*



динов, Хисаметдин Исмәгыйлев, Фәнирә Ибраһимова, Лилия Сабитова, Мансур Гыйззәтуллинның шигырь-хикәяләре бер тында укыла. "Таныш булыгыз" бүлегендә әдәбият, шигърият дөньясына аяк басып, үзләренең каләмнәрен сынарга килүчеләргә урын бирелгән. Алар арасында исемнәре газит-журналларда күренгән Эльвира Батырова, Гөлсинә Басыйрова, Зөлфия Гомәровалар белән беррәттән Эльвина Дашкина, Айсылу Хөбетдинова кебек яшь каләм тибрәтүчеләрнең шулай ук Алмас Шаммасның булуы аеруча күңелле. Димәк, киләчәктә дә шигъриятнең яшәячәгенә ышаныч бар. Ә инде сиксән яшән куган Сәрия апа Зиннәтуллинаның зур кызыксыну уяткан, дөреслек, гаделлек ярылып яткан шигырьләре аларга үрнәк булып торырлык. Менә нинди хисләр тудырган бу китап Гаян Арслановта. Аның әле кыскартылып бирелгән шушы бәянамәсе "Бер китапта күпме байлык" исемендә "Кызыл таң"гәзитенең 2010 елның 6 апрель санында дөнья күрде. Ә 1 августта чыкканында билгеле журналист Әхнәф Әминев Римма белән Ягъфәрне "Стәрлебашның маягы алар" дип белдереп, якташларына фәкать изгелек кылучы, шатлык-куанычлар өләшүче бу матур гаиләне киләчәктә дә уңышлар, бәхет көтеп торуын тели.

Аның теләкләрен һич онытмый, тормышка ашыруын дәвам итә Ягъфәр.

2012 елның җөенә аяк басу белән инде Татарстан Язучылар берлеге белән элемтәгә керә. Күп тә үтми, фондның идарә әгъзалары Рәфгать Рысаев белән Хисаметдин Исмәгыйлевны үз машинасына утыртып, Казанга алып китә. Анда берлек рәисе Рәфис Корбан белән танышып, районашларының иҗат җимешләрен матбугатта басып чыгару хакында килешүгә ирешелә. Шуннан кайтып авторлардан материал җыялар да, Казанга илтеп бирәләр. Нәтиҗәдә татар халкының төп әдәби журналы – "Казан утлары"ның ноябрь аенда чыккан 11нче санының "Бездә кунакта – Башкортстанны Эстәрлебаш районы әдәби берләшмәсе" дип исемләнгән бүлеге районыбызның шөһрәтен бөтен татар дөньясына таратты.



*Я.С. Хисмәтуллин классташлары белән очрашуда. 2013 ел, июнь ае.*

Бүлектә тәүге сүз район хакимияте башлыгы Фәнүр Туктаровка бирелеп, туган төягебезнең тарихы һәм бүгенге көнкүреше, шул исәптән Акмулла фондының эшчәнлеге дә тасвирланган “Эстәрлебаш Казаннан ерак түгел” дигән мәкаләсе урын алган. Аннан соң журнал битләрен Рәфис Зыязетдинов, Фәнирә Ибраһимова, Наилә Гыйззәтуллина, Зөлфия Гыйзетдинова, Гөлсинә Басыйрова, Гаян Арсланов, Лилия Сабитова, Рәис Байгилдин, Гаяз Уляев, Хәлимә Назарова шигырьләре, Рәфгать Рысаев, Мәҗит Кәримов, Хисаметдин Исмәгыйлев хикәяләре тулыландыра.

Шушы ук 2012 елның ноябрь ае районыбыз тормышына тагын зур шатлык өстәде – 28 ендә Казанда Камал театрына Акмулла исемендәге премия тапшырылды. Ә 2013 елның 1 мартында Стәрлебаш үзе Татарстан Язучылар берлеге рәисе Рафис Корбан җитәкчелегендә килгән кунакларны ко-



лач җәеп, җыр-моң, чәк-чәк һәм кымыз белән каршы алды. Район Мәдәният йортында үткән “Түгәрәк өстәл” артында алар Башкортстан Язучылар берлеге рәисе Риф Тойгын һәм Хәсән Назар, Фәнил Күзбәков, Мөхәммәт Закиров, Мидхәт Әбделмановлар белән татар һәм башкорт әдәбиятлары арасында дуслыкны ныгыту, бүгенге көн проблемалары хакында фикер алышты. Шулай ук ике каләмкяребез – Рәфгать Рысаев белән Хисаметдин Исмәгыйлевны Татарстан Язучылар берлегенә кабул итү мөмкинлеге, аларның иҗаты, әдәбиятка керткән өлешләре тикшерелеп, икесе дә моңа лаек дип табылды. Һәм 24 майда аларга Казанда Татарстан язучыларының еллык хисап җыелышында әгъзалык таныклыгы тапшырылды.



***Күңел җимешләре «Язма гөл чәчәкләре»ндә басылган бер төркем авторлар.***

***Беренче рәттә утыралар - сулдан уңга: Фәрит Зарипов, Нәгыйм Ярмөхәммәтов, Мәҗит Кәримов, Тимербулат Мөхәммәткулов.***

***Басып торалар: Фәрит Әхмәтов, Рәфгать Рысаев, Гаяз Уляев, Фәнүр Галимов, китапны нәшир иттерүче Ягъфәр Хисмәтуллин, Гаян Арсланов, Рәфис Зыязетдинов, район гәзите мөхәррире Мансаф Ганиев.***



*Г.Камал татар театры коллективын каршы алу вакыты.*

Акмулла фонды Башкортстанның яшьләр журналы "Тулпар"ның шигърият бүлеге мөхәррисе Мөнир Вафинны чакырып китереп, район иҗатчылары белән очраштырды. Мөниргә дә хуш килде бу аралашу һәм аның нәтиҗәләрен "Тулпар"ның 5 санында бар укучылары карамагына чыгарды.

Бу бүләк тә Мөнир Вафинның район башлыгы Ф.Туктаров үткәргән әңгәмәсе белән башлана. "Стәрлебаш-борынгы төбәк" – дип атала ул һәм төбәгебезнең тарихы һәм бүгенге үзәнчәлекләре яктыртыла.

Аннары "Кызарып ла пешкән миләштән өзелеп лә төшкән тәлгәшләр"–Рәфгать Рысаев белән Зәлфия Гыйзетдинованың шигъри гөлләмәләре, Хисаметдин Исмәгыйлевның "Сөлдә" хикәясе, "Көз килүгә горур тауларның да Түбәләре кала ялангач..." дип чигәдәге чәчләре агарганга артык исләре китмәгән Фәрит Әхмәтов, Флүрә Хәлиуллина – Сәлимова, Гаян Арсланов, Гаяз Уляевның кучтәнәчләре сөендерә.



Ягъфәр Хисмәтуллин исә: "Мәдәниятле халык кына акыллы җәмгыять төзи ала" – дип исбатлый һәм Акмулла фондының эшчәнлеген мисалга китерә.

Ә Мөнир Вафинның Стәрлебашка яшәргә кайткан танылган язучы Зәки Зәйнуллин белән әңгәмәсе юкка гына "Тамырларым туган җирдә" дип исемләнмәгән. Анда Стәрлебаш мәдрәсәләренең татар, башкорт халыкларының төп мәгърифәт үзәге булуы тулысынча раслана һәм үзенең дә шул җирдә мәңгелек йортта яшәү теләге сокландыра.

Әңгәмәдән соң басылган "Сугыш чукмары", "Өйләнү", "Кияү", "Чалатай бабай" хикәяләрендә дә Стәрлебаш кешеләренең төрле чордагы яшәешләрен тасвирлап, туган авылының абруен күтәрә Зәки Зәйнуллин.

Шулай ук Татарстан Фәннәр академиясенең Г.Ибраһимов исемендәге Тел, Әдәбият һәм сәнгать институтының "Ерак еллар кайтавазы" монографиясе безнең тарихта эзле төбәктә яшәвебезне яңа ачышлары белән тагын да горурландыра.

Инде килеп "Стәрлебаш мәзәкчеләре җыены" кызыкмызыклары белән көлдерә дә, уйландыра да Фәйзи Гомәрнең "Кыйммәтле сабак", "Рәнҗетәләр", Рәфгать Рысаевның "Ярты җир чәчелмәсә дә" шигырьләре, Сәрия Зиннәтуллинаның "Замана такмаклары"белән.

Ә журнал тышлыгының эчке ягындагы Зәки Зәйнуллинның Искәндәр Нигъмәтҗанов төшергән сурәте һәм иң уртадагы төсле фотолардан торган Стәрлебашның тарихи ядкарьләре битләре карап туярлык түгел.

Боларга өстәп, тагын да шуны әйтәсе дә килә, бишенче санына гына сыймаган икән Нуридә Насыйбуллинаның кулъязмасы, аның дәвамы, бигрәк тә Муса Җәлилнең дә Рәмиевлар нәселеннән булуы хакындагы ачышлары "Тулпар"ның 6 нчы санында басылды.

Әлеге вакытта Хисматуллин Я.С. районның атаклы кешеләре турында әзерләп китап чыгарырга материаллар туплый. Анда 100 ләп кешенең биографияләре, казанышлары турында бәяп ителә.



Мин, **Шарипова (Арсланова) Гөләмзә Мотыйгулла кызы** 1945 нче елны 10 июлендә Башкорт АССРы Стәрлебаш районы Тәтер – Арслан авылында туып үскәнмен.

Шушы авылда укып 1963 елны урта мәктәпне бетереп Салават тегү фабрикасында эшләдем. 1964 – 1967 елларда Стәрлетамак медицина училищесендә укып фельдшер һөнәренә ия булдым. 1967 елның Стәрлебаш район Үзәк больницасында эшләп 1968нче елны туган авылым Тәтер – Арслан участок больницасында 2000нче елга кадәр фельдшер – акушерка вазыйфасын башкардым.



Тормыш иптәшем Арсланов Венер Мансур улы белән ике кыз үстердек, Лилия һәм Зәлия кызларыбыз. 2000нче елдан алып лаеклы ялдамын.

**Шигапова Миненур Кәррәм кызы** 1946нчы елның 1нче гыйнварендә Айдәрәле авылында күмәк балалы колхозчы гаиләсендә туган. Айдәрәле җидееллык мәктәбен тәмамлагач, берничә классташы белән күрше Т – Арслан урта мәктәбендә укуын дәвам итә.

Урта белемле булганнан соң, Кырмыскалыда бер еллык





бухгалтерлар курсын тәмамлый. Аны Федоровка районына эшкә җибәрәләр. Пугачев совхозының Юрматы бүлегендә эшли башлый.

1965 нче елда гаилә коралар, ә бер елдан ире Хәмит белән Казахстанга китәләр. Җизказган өлкәсенә барып урнашалар. Хәмит шахтада, ә Миненур заводта эшлиләр. Миненурга мастер булып та, складта да эшләргә туры килә. 1978 нче елдан курсларда алган белеме буенча эшли башлый. Миненурның тырышлыгын, үз эшенә җаваплы каравын ул эшләгән коллектив тиз күреп ала. Бу чакта аның күпсанлы Почет грамоталары, рәхмәт хатлары сөйли. Ленинның тууына 100 ел тулу уңаеннан бирелгән медальга да лаек була ул.

Рәсеме Почет тактасында еш эленеп тора, шәһәр советына депутат итеп сайлана. Хезмәт ветераны.

Гаиләдә Лира исемле кыз, Радик исемле ул үсә. Лира фельдшерлык һөнәрен ала, Радик Җизказган тау техникумында белем ала.

Хәзерге вакытта Миненур Стәрлебашта яши. Ире Хәмит вафат булгач, туган ягына кайтырга, туганнары арасында яшәргә тиеш саный.

Кызы Лира да бер ул, бер кыз үстерә. Алар да Стәрлебашта яшиләр. Лира район больницасында эшли.

Радик хәзерге вакытта Когалымда үзенең укып алган һөнәре буенча эшли. Гаиләсе Стәрлебашта. Радикларның ике кызлары бар. Олысы Германияда яши гаиләсе белән. Кечесе үзләре белән, әле укуын дәвам итә.

Лираның да ике оныгы үсеп килә.

# ЭЧТӘЛЕК .


1. Әз генә тарих 1-5
2. Класс турында 5-9
3. Мәктәп директоры һәм аның хатыны 10-13
4. Класс җитәкчесе 13
5. Аглиуллина Н.Б. 13-14
6. Ахмадеев Т.Х. 15-16
7. Арсланова Х.Х. 16
8. Ахметова Н.А. 17-34
9. Гайнетдинов Ф.Г. 34-35
10. Булатова Р.Г. 35-36
11. Давлетъяров Г.С. 36-37
12. Ибрагимов Ф.Ш. 37-39
13. Ишмухаметов Н.Б. 39-40
14. Султанов Р.К. 40-41
15. Мавликаева Г.С. 41-42
16. Мифтахов И.З. 42-45
17. Мулюкова Ә.Ш. 45
18. Муллагалеев М.З. 46
19. Нугманов М.М. 46-54
20. Хисматуллин Я.С. 54-67
21. Шарипова Г.М. 68
22. Шигапова М.К. 68-69

КЛАССТАШЛАР

Составитель Ягъфар Хисматуллин.
Компьютерная версткаРасиля Хабибуллина

Басарга кул куелды 18.05.2018 ел.
Тираж 50. Заказ №1479

Стерлитамакская городская типография.